МИНИСТЕРСТВО ТРАНСПОРТА И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ ХУҖАЛАГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**БОЕРЫК** **ПРИКАЗ**

от «17» 08.2016 № 253

Казан шәһәре

«Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәне раслау турында» 2015 елның 12 октябрендәге 396 номерлы Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый совет турында» 2010 елның 18 ноябрендәге 906 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый совет турында үрнәк нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында» 2015 елның 17 ноябрендәге 862 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 2015 елның 12 октябрендәге 396 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3.пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Иҗтимагый совет составына, Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санының биштән береннән артык булмаган күләмдә, элек Россия Федерациясе дәүләт вазыйфаларын, Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт хезмәте вазыйфаларын, муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләгән затлар кертелергә мөмкин.»

Министр Л.Р.Сафин